**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31.01.2024 № 111

2024 елда Нурлат муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру турында

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Нурлат муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның балансы кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024-2026 елларга түләүләрнең айлык акчалата һәм башка төрләре турында» 2023 елның 07 сентябрендәге 1099 номерлы карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елга Нурлат муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар өчен һәр уку көненә 66 сум 76 тиен суммасына бушлай туклану оештырырга.
2. 2024 елга Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын туклындыруга Нурлат муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен һәр уку көненә 9 сум 20 тиен күләмендә билгеләргә.
3. "Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы" муниципаль казна учреждениесенә 2024 елга Нурлат муниципаль районы бюджетында каралган ассигнованиеләр чикләрендә гомуми белем бирү оешмаларының барлык укучылары өчен уку вакытында туклануны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны гамәлгә ашырырга.
4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
5. Әлеге карарны куллану буенча контроль Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К.Габдуллин